ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.200, с. Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

КӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урам, 200 нче йорт, Кәче авылы,

Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93 E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

---

КАРАР

«22» ноябрь 2018 ел № 26

**“Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда кабул ителгән 2018 елның 18 нче ноябрендәге 6 нчы (нче) номерлы карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. “Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгарырга, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк урам, 200 нче йорт; Чулпан авылы, Гагарин урамы 22а йорты; Якты-Көн авылы, Якты урамы 30а йорты адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат такталарына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кәче авыл
җирлеге башлыгы Закиров Т.Д.

Кәче авыл җирлеге
башкарма
комитетының 2018
елның 22 нче
ноябрендәге
26 нчы номерлы
карарына 1 нче
кушымта

**“Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип “Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Үзара салым акчасы 18 яшькә җиткән һәм “Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, җирле референдумда катнашу-катнашмауга, тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2019 елның 21 нчы февраленә кадәр түләнә.

3. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә укучы студентларга,

б) 75 яшьтән өлкән гражданнарга,

түләү күләме җирле референдум карарында билгеләнгән сумманың 50% процентын тәшкил итә.

4. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (эти-энисе, тормыш иптәше, балалары) үлеме,

б) янгыннан һәм башка бәлә-казадан зыян күрү,

өч айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Татарстан Республикасы хокук, мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгару, Арча муниципаль районы рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк урам, 200 нче йорт; Чулпан авылы, Гагарин урамы 22а йорты; Якты-Көн авылы, Якты урамы 30а йорты адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат такталарына урнаштыру, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша халыкка җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

6. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары “Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге шәхси хисабына күчерелә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыруга һәм почта аша күчерүгә хокуклы оешмалар, Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша башкарыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Билгеләнгән вакытта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.